РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 8 декабре № 49

## Түбән Кама шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре Уставының 6 статьясы нигезендә, күчемсез милек хокук ияләренең һәм күчемсез милек объектлары белән идарә итү, файдалану, эш итү хокукын алырга теләгән затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү максатларында, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2010 елның 22 декабрендәге 20 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 әлеге карарга кушымта нигезендә, Түбән Кама шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең картографик материалларына;

1.2 Түбән Кама шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең текстлы материалларына:

25 статьяда:

Ж-3 территориаль зонасын төп рөхсәт ителгән файдалану төрләре исемлегендә «5-9 катлы күпфатирлы торак йортлар;» сүзләрен «беренче катны (яки ике беренче катны) бизнес, сәүдә һәм башка хезмәт күрсәтү төрләре белән шөгыльләнү өчен файдалану белән 5-9 катлы күпфатирлы торак йортлар» сүзләренә алмаштырырга;

27 статьяда:

ПК-1 территориаль зонасы җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары иң чик параметрлары таблицасының «Корылмаларның кишәрлекнең ян чикләреннән чигенүе» юлын «в) нефть химиясе производствосы технологик процессының бер өлеше булган нефть химиясе сәнәгате объектларын урнаштыру өчен – корылмаларның җир кишәрлегенең ян чикләреннән чигенүе билгеләнми» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының шәһәр инфраструктурасын үстерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры
вазыйфаларын башкаручы,
Мэр урынбасары М.В. Камелина

Түбән Кама шәһәр Советының
2022 елның 8 декабрендәге
49 номерлы карарына
кушымта

Түбән Кама шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең картографик материалларына кертелә торган үзгәрешләр

| т/с | Җир кишәрлекләре, К№ | Үзгәрешләргә кадәр территориаль зона | Үзгәрешләрдән соң территориаль зона | Планлаштырыла торган чара |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 16:30:010803 | Р-1 Рекреация - ландшафт территорияләре зонасы | Д-1 Эшлекле, иҗтимагый һәм коммерция билгеләнешендәге зона | сәүдә һәм хезмәт күрсәтү объекты |
| 2 | 16:53:040101 | Д-2 Сәламәтлек саклау һәм социаль билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы | Д-1 Эшлекле, иҗтимагый һәм коммерция билгеләнешендәге зона | административ-хуҗалык бинасы |
| 3 | 16:30:011402:70 | СН-5 Махсус билгеләнештәге яшелләндерү зонасы | ПК-2 III куркынычлык классы җитештерү-коммуналь объектлар зонасы | җитештерү базасы |
| 4 | 16:53:010103:40<br>16:53:010103:43<br>16:53:010103:47 | Ж-1 Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы | ПК-3 IV-V куркынычлык классы җитештерү-коммуналь объектлар зонасы | җитештерү базасы |
| 5 | 16:53:040306 | Д-1 Эшлекле, иҗтимагый һәм коммерция билгеләнешендәге зона | ИТ-4 Транспорт инфраструктурасы объектлары зонасы | машина кую урыны |

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары М.В.Камелина